Республика Татарстан
Глава
Вахитовского сельского поселения
Азнакаевского муниципального
района

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге
башлыгы

ул.Центральная, д. 30, пос.Победа
Азнакаевский район, 423312

Үзәк урамы, 29 нче йорт, Җиңү
бистәсе, Азнакай районы, 423312

Тел. (факс) 8(85592) 42-1-38; e-mail: Vahit.Azn@tatar.ru
http://aznakayevo.tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«24» ноябрь 2021 ел. №8

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Чәкән торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Уставынын 15.1 статьясы нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Чәкән торак пункты, Базарная урамы, 2 нче йорт адресы буенча урнашкан Чәкән мәдәният йорты бинасында 2021 елның 5 декабрендә 13.00 сәгать 00 минутта Чәкән авылы Базарная урамы 1 йорттан 27 йортка, Бәйрәкә урамы 1 йорттан 17 йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Җиңү торак пунктында 2022 елда гражданнарның узара салымын кертү мәсьәләсе буенча **гражданнар җыенының беренче этабын** билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Чәкән торак пункты, Базарная урамы, 2 нче йорт адресы буенча урнашкан Чәкән мәдәният йорты бинасында 2021 елнын 5 декабрендә 14.00 сәгать 00 минутта Чәкән авылы Большая урамы 1 йорттан 27 йортка, Комаровка урамы 1 йорттан 21 йортка, Маленькая урамы- барлык йортлар, Новая урамы 1 йорттан 25 йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Җиңү торак пунктында 2022 елда гражданнарның узара салымын кертү мәсьәләсе буенча **гражданнар җыенының икенче этабын** билгеләргә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез, 2022 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның толл хатыннары,

көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Чәкән торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Чәкән торак пунктында урамнарны яктыртуны карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, лампаларны, яктырткычларны сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);

- Чәкән авылында бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (бүләк сувенир продукциясе сатып алу, «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Яңа ел» бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтү).

- Чәкән торак пунктында юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) ;

« РИЗА» «КАРШЫ».

4. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Вахитов авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Азнакай районы Вахитов
авыл җирлеге башлыгы И.Б. Бохарова